РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Исполнительный комитет**
***Старобарышевского***
***сельского поселения***
Камско-Устьинского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Кама Тамагы
муниципаль районы
***Иске Барыш***
***авыл җирлеге***
**Башкарма комитеты**

422835, с. Старое Барышево, ул.Центральная, 15
тел.(884377)30-3-18, ИНН/КПП 1622004570 / 162201001 ОКПО 93064659 ОГРН 1061672003436

422835, Иске Барыш авылы, Үзәк урамы, 15
тел.(884377)30-3-18, ИНН / КПП 1622004570 / 162201001 ОКПО 93064659 ОГРН 1061672003436

---

КАРАР

«7» декабрь 2021 ел № 17

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенең Кыртапа авылында 2022 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама-Тамагы муниципаль районы Кыртапа авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенә кергән Кыртапа торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2021 елның 17 нче декабренә 13.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндэге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенә кергән Кыртапа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә яшәмәүче һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 2022 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

1) Кыртапа авылы урамнарның яктырту объектларын карап тоту (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу);
2) юлларны кардан грейдлау, чистарту (ягулык-майлау материаллары, фронталь төягеч һәм бульдозер отвалы трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).;

3) җәйге чорда территорияне чабу (КРН-2,1 Б ротацион чапкычлы трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).;

4) МТЗ 82.1 тракторына арткы чүкеч (асылмалы җиһазлар) сатып алу.

5) Кыртапа авылын төзекләндерү ( йоклау, коры агачлар кисү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

« ӘЙЕ» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Иске Барыш авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.Р.Җиһаншин**